**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Ивашкино авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлегенең
Ивашкино торак пунктында 2026 елда үзара салым кертү турында

17 октябрь 2025 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлегенең Ивашкино торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. 2026 елда Ивашкино авыл җирлегенең Ивашкино авыл территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасында һәм Донецк халык республикасында махсус операциясендә булган затлардан, 1 төркем инвалидлардан, ялгыз өлкән яшьтәге һәм 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш.

1. Алынган чараларны түбәндәге эшләргә җибәрергә:

- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, бензин алу, триммер, триммер өчен запас частьләр сатып алу һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, парк коймаларын ремонтлау һәм буяу, Ивашкино торак пунктында ике дәүләт телендә (рус һәм татар телләрендә) йорт номерлары һәм урам исемнәре язылган табличкалар әзерләү һәм урнаштыру, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;
- **торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (Ивашкино торак пунктында җирле әһәмияттәге урам юлларындагы чокырларны ремонтлау, ясалма тигезсезлекләр төзү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- **урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау** (Ивашкино торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру, кулланыла торган электр энергиясе өчен урамнарны яктырту

чыгымнарын түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәтләр өчен түләү.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
ТР Чирмешән муниципаль районы
Ивашкино авыл җирлеге башлыгы Ф.П. Андреев